СОВЕТ БОЛЬШЕШУРНЯКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОЛЫ ШУРНЯК
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ с. Большой Шурняк (Олы Шүрнәк) КАРАР

№ 76 16 декабрь 2022 ел

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Шүрнәк авыл җирлеге Советының 2009 ел 30 декабрендәге 17 номерлы "Алабуга муниципаль районы Олы Шүрнәк авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә яшел үсентеләрне булдыру, карап тоту һәм саклау кагыйдәләрен раслау турында"гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «әйләнә-тирә мохитне саклау турында» Россия Федерациясе Законы, Россия Федерациясе Урман кодексы, Россия Федерациясе Җир кодексы нигезендә, Алабуга муниципаль районы Олы Шүрнәк авыл җирлеге территориясендә үсә торган яшел үсентеләрне куллану һәм саклау процессын тәртипкә китерү максатларында, Алабуга шәһәр прокуроры таләпләрен карап, Олы Шүрнәк авыл җирлеге Советы

Карар итте:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Шүрнәк авыл җирлеге Советының 2009 ел 30 декабрендәге 17 номерлы "Алабуга муниципаль районы Олы Шүрнәк авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә яшел үсентеләрне булдыру, карап тоту һәм саклау кагыйдәләрен раслау турында"гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 бүлекнең 5.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.6. Яшел үсентеләрне кисүне күздә тоткан рөхсәтнең гамәлдә булу вакыты эшнең катлаулылыгына һәм күләменә карап ике елга кадәр билгеләнә.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Рәис Н. И. Мельников